ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.06.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1297**

2019/2020 елның ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларын 2019/2020 елның ягып җылыту чорына әзерләү бурычлары турында» 2019 елның 17 июнендәге 496 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019/2020 елның ягып җылыту чорына җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның әзерлеген тикшерү буенча, кушымтада каралганча, комиссия төзергә.
2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С. Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының карарына
_______ № _______

Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның 2019/2020 елгы ягып җылыту чорына әзерлеген тикшерү комиссиясе составы

**Комиссия рәисе:**
Сапожников Д.А. - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе
**Комиссия рәисе урынбасары:**
Кадникова Э.Р. - Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары
**Комиссия секретаре:**
Антонов А.О. - «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе
**Комиссия әгъзалары:**
1. Афанасьева Р.В. - җитәкче урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы
2. Лулаков Д.В. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары
3. Нурмөхәммәтов А.З. - «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе
4. Зиннуров Р.Н. - «Зеленодольск муниципаль районының техник күзәтчелек хезмәте» МУП директоры
5. Хәбибуллин И.И. - Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге башлыгы
6. Цветкович М.М. - Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге өлкән дәүләт инспекторы
7. Ситдыйкова А.Р. - Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы
8. Габдуллаҗанова А.А. - Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы
9. Маер Н.Л. - «Зеленодольск ПТС» АҖ башкарма директоры (килешү буенча)
10. Кулькова Е.Н. - «Торак-коммуналь хезмәтләр» ҖЧҖ директоры (килешү буенча)
11. Бәхтияров Р.Р. - «Норлат МПП ЖКХ» МУП директоры (килешү буенча)
12. Гыйззәтуллин Л.Р. - «Нижневязовская жилкомсервис» ҖЧҖ директоры (килешү буенча)
13. Васев В.М. - «Осиново җылылык белән тәэмин итүче компания» ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча).